# Universal Declaration of Human Rights - Tatar ()

---

## Кеше хокуклары хартиясе

### I. Кеше хокукларының гомуми декларациясе

Берләшкән Милләтләр Оешмасының Генераль Ассамблеясе 1948 елның 10 декабрендә 48 тавыш белән кабул итте. Анда сигез кеше бер якка да тавыш бирмәде.

Преамбула.

Кешелек гаиләсенең бөтен әгъзаларына хас булган тигез һәм аерылгысыз хокукларны һәм кеше дәрәҗәсен тануның гаделлек һәм гомуми тынычлыкның нигезе икәнен *истә тотып,*

кеше хокукларына кимсетеп һәм җирәнеп карауның вәхшилеккә китерүен, кешелек намусын уятуын, кешеләрнең үз карашларына һәм сүз иреген ия булган, куркудан, мохтаҗлыктан азат булган тормыш төзүнең кешеләрнең боек омтылышы икәнен игълан итүне истә тотып.

җәберләүгә һәм изелүгә каршы соңгы чара итеп кеше баш күтәрергә мәҗбүр булмасын өчен аның хокукларын закон көче белән саклау зарурлыгын *истә тотып,*

Кешенең төп хокукларына, шәхеснең абруена һәм кыйммәтенә, хатын-кызларның һәм ирләрнең тигез хокуклылыгына, Берләшкән Милләтләр халыклары үзләренең ышанычын Уставта раславын һәм тагын да зуррак иреккә ирешеп, иҗтимагый үсешкә, тормыш шартларын яхшыртуга ярдәм итәргә ниятләвен *истә тотып,*

Берләшкән Милләтләр Оешмасы әгъзасы булган дәүләтләрнең кеше хокукларын, төп ирекләрне уртак хөрмәт итүдә һәм саклауда булышлык күрсәтүне үз бурычлары итеп алуларын *истә тотып,*

әлеге хокукларны һәм ирекләрне аңлау бу йөкләмәләрне тулысынча үтәүдә бик зур әһәмияткә ия булуын *истә тотып,*

Генераль Ассамблея

әлеге Кеше хокукларының гомуми декларациясен бөтен дәүләтләр һәм халыклар үтәргә омтылырга тиешле бурыч сыйфатында игълан итә. Бу Декларацияне һәрвакыт күз алдында тотып, җәмгыятьнең һәр әгъзасы, һәр кеше аң-белем тарату, белем алу юлы белән бу хокукларны һәм ирекләрне хөрмәт итәргә тиеш, бу хокуклар һәм ирекләр Оешма әгъзасы булган дәүләтләр халкы һәм алар юрисдикциясендә кергән территорияләрдәге халыклар арасында алдынгы милли һәм халыкара чаралар аша тулаем һәм нәтиҗәле танылып тормышка ашырылырга тиеш.

1 статья.

Барлык кешеләр дә азат һәм үз абруйлары һәм хокуклары ягыннан тиң булып туалар. Аларга акыл һәм вөҗдан бирелгән һәм бер-берсенә карата туганарча мөнәсәбәттә булырга тиешләр.

2 статья.

Һәр кеше үзенең милли яисә иҗтимагый чыгышына, мөлкәтенә, нинди катлаудан булуына, расасына, тән төсенә, җенесенә, теленә, диненә, сәяси яисә башка инануларына карамастан, бернинди аермасыз, Декларациядә игълан ителгән барлык хокукларга, бөтен ирекләргә ия булырга тиеш. Моннан тыш, кешенең торган җиренең мөстәкыйль яисә үзидарәсез, берәр ил карамагында булуына яисә мөстәкыйльлеге башка берәр төрле чикләнүенә карамастан, иленең сәяси, халыкара, хокукый хәленә карамастан, аңа бернинди дә аерымлау үткәрелергә тиеш түгел.

3 статья.

Һәр кешенең тормышка, ирекка һәм шәхси кагылгысызлыкка хокукы бар.

4 статья.

Бер кеше дә коллыкта яисә ирексез хәлдә тотылырга тиеш түгел; коллыкның һәм коллар сатуның бөтен төрләре тыела.

5 статья.

Беркем дә газапланырга, яусыз, кешелексез яисә аның дәрәҗәсен төшерә торган мөнәсәбәткә дучар ителергә һәм җәзага тартылырга тиеш түгел.

6 статья.

Һәр кешенең, ул кайда гына булса да, үзенең хокук иясе икәнен тануларын таләп итәргә хакы бар.

7 статья.

Закон алдында бөтен кешеләр дә тиң, бернинди аерымланусыз һәркемнең закон белән тигез якланырга хокукы бар. Барлык кешеләрнең дә бу Декларацияне бозучы нинди дә булса хокуклардан мәхрүм ителүдән, шундый хокуклардан мәхрүм итүгә котыртудан тигез якланырга хокуклары бар.

8 статья.

Конституция яки закон биргән төп хокуклардан мәхрүм ителгән очракта, һәр кешенең ул хокукларын компетентлы милли судлар аша кире кайтарылып бирелүен таләп итәргә хокукы бар.

9 статья.

Беркем дә нигезсез рәвештә кулга алынуга, тоткарлануга, куылуга дучар ителергә тиеш түгел.

10 статья.

Һәр кешенең үз хокукларын һәм бурычларын билгеләр өчен һәм аны җинаять җаваплылыгына тартуның нигезле булуын ачыклар өчен, тулы тигезлелек нигезендә үз эшенең ачык рәвештә, мөстәкыйль, гадел һәм бәйсез суд аша каралуын таләп итәргә хокукы бар

11 статья.

1. Җинаять кылуда гаепләнүче һәр кеше, аның гаебе ачык суд тикшерүе нәтиҗәсендә законлы рәвештә расланганчы гаепсез дип саналырга хакы бар. Аңа суд тикшерүе вакытында яклану өчен бөтен шартлар тудырылырга тиеш.

2. Берәр эш эшләгән өчен, яки эшләмәгән өчен гаепләү, ул эшләрне кылу вакытында милли законнар алдында яки халыкара хокук алдында җинаять итеп саналмаса, алар өчен бер кеше дә җавапка тартыла алмый. Беркемгә дә җинаять эшләгән өчен тиешле җәзадан да катырак җәза бирелергә тиеш түгел.

12 статья.

Бер кеше дә шәхси һәм гаилә тормышына, торак иминлегенә кагылуга, язышу, хәбәрләшү серенә, абруена һәм намусына нигезсез кагылуга дучар ителергә тиеш түгел. Шундый кысулардан, яисә дучар ителүләрдән һәр кешенең закон белән якланырга хокукы бар.

13 статья.

1. Һәр кешенең һәр дәүләт чикләре эчендә ирекле күченеп йөрергә һәм үзенә тору урыны сайларга хокукы бар.

2. Һәр кешенең теләсә кайсы илне, яисә үз илен ташлап китәргә һәм үз иленә кире әйләнеп кайтырга хокукы бар.

14 статья.

1. Һәр кешенең җәберләнүдән башка илләрдә сыену урыны эзләргә һәм ул урыннан файдаланырга хакы бар

2. Сәясәт белән бәйле булмаган җинаять кылган очракта яисә Берләшкән Милләтләр Оешмасының принцибына, максатына каршы килә торган җинаять кылса, кеше бу хокуктан файдалана алмый.

15 статья.

1. Һәр кешенең гражданлыкка хокукы бар.

2. Берәү дә ирексездән үз гражданлыгыннан яисә гражданлыгын үзгәртү хокукыннан мәхрүм ителергә тиеш түгел.

16 статья.

1. Яше житен балигъ булган ирләрнең һәм хатын-кызларның, милләтенә, диненә яисә расасына карамастан, бернинди чикләүләрсез, өйләнешүгә һәм гаилә корырга хокуклары бар. Алар өйләнешкәндә дә, бергә торганда да, аерылышу вакытында да бер үк төрле хокуклардан файдаланалар.

2. Өйләнешүчеләрнең языльшуы икс якның да ирекле һәм тулы ризалыгы булганда гына тормышка ашырыла.

3. Гаилә җәмгыятьнең табигый һәм төп күзәнәге булып тора, аның җәмгыять һәм дәүләт ягыннан якланырга хокукы бар.

17 статья.

1. Һәр кеше үзе генә дә, башка кешеләр белән бергәләп тә, мал-мөлкәткә ия булу хокукына ия.

2. Беркем дә үз мөлкәтеннән нигезсез мәхрүм ителергә тиеш түгел.

18 статья.

Һәр кешенең фикер, вөҗдан һәм дин ирегенә хокукы бар; бу хокук Аллага табынуны, йола куша торган дини тәртипләрне үтәүне эченә ала, һәр кешенең бер үзе генә яисә башкалар белән бергәләп аерым рәвештә яки ачыктан-ачык үз карашларын, үз динен алыштырырга яки тотарга хокукы бар.

19 статья.

Һәр кешенең ирекле фикер йөртергә һәм карашларын ирекле рәвештә әйтергә хокукы бар; бу хокукка үз карашларында ирекле булу, үзенә кирәкле мәгълүматны һәм идеяләрне эзләү, табып алу, төрле юллар белән дәүләт чикләренә бәйсез рәвештә тарату да керә.

20 статья.

1. Һәр кеше тыныч рәвештә җыелышлар һәм ассоциацияләр ирегенә хокуклы.

2. Берәү дә нинди дә булса ассоциациягә керергә мәҗбүр ителә алмый.

21 статья.

1. Һәр кешенең турыдан-туры яисә ирекле сайланган вәкилләр аша үз иле белән идарә итәргә хокукы бар.

2. Һәр кешенең үз илендә бертигез рәвештә дәүләт хезмәтенә керү хокукы бар.

3. Халык ихтыяры хөкүмәт хакимлегенең нигезе булырга тиеш; әлеге ихтыяр үзенең чагылышын үз вакытында үткәрелә торган гадел сайлауларда табырга тиеш. Тавыш бирү яшерен, гомуми һәм тигез

сайлаулар аша, яисә шуңа тиң булган башка формаларда тәэмин ителергә тиеш.

22 статья.

Һәр кеше, җәмгыять әгъзасы буларак, социаль тәэмин ителүгә һәм дәүләт структурасына һәм табигый байлыкларына карап, халыкара хезмәттәшлек һәм милли тырышлыклар аша социаль, икътисади һәм мәдәни яктан үз шәхесенең ирекле үсеше өчен, дәрәҗәсе төшмәслек кирәкле ярдәмгә хокуклы.

23 статья.

1. Һәр кешенең хезмәткә, эшне ирекле рәвештә сайлап алуга, гадел һәм уңайлы эш шартларына һәм эшсезлектән яклануга хокукы бар.

2. Һәр кеше, бернинди кимсетелүләрсез, тигез эш өчен тигез хезмәт хакы алырга хокуклы.

3. Һәр хезмәт кешесе үзенә һәм гаиләсенә кешегә лаеклы көн күрерлек гадел һәм канәгатьләнерлек түләү алырга, кирәк очракларда өстәмә рәвештә башка чаралар белән дә социаль тәэмин ителергә хокуклы.

4. Һәр кешенең һөнәри берләшмәләр оештырырга һәм үзенең мәнфәгатьләрен яклар өчен һөнәри берләшмәләргә керергә хокукы бар.

24 статья.

Һәр кеше ялга хокуклы һәм эш көнен тиешле чикләрдә кыскартуны да кертеп, ел саен түләүле ял алырга, эштән буш вакытка хокукы бар.

25 статья.

1. Һәр кеше тормыш дәрәҗәсен төшермәслек булган туклануга, киемгә, торакка, медицина ярдәменә, социаль хезмәт күрсәтелүгә, үзенә һәм гаиләсенә сәламәтлек, мул тормыш тәэмин ителүгә хокуклы. Эшсез калган очракта, авырганда, гарипләнгәндә, тол калганда, картайганда һәм башка төрле үзенә бәйләнмәгән сәбәпләр белән тормыш итү чараларын югалтканда һәр кешенең тиешле ярдәм алырга хокукы бар.

2. Ана булу һәм сабыйлык аерым тәрбиягә һәм ярдәмгә хокук бирә. Никахлы һәм никахтан тыш туган барлык балалар бердәй социаль якланганлыкка ия.

26 статья.

1. Һәр кеше белем алырга хокуклы. Бигрәк тә башлангыч һәм гомуми белем алу бушлай булырга тиеш. Башлангыч белем алу мәҗбүри булырга тиеш. Техник һәм профессиональ белем алу һәркем

өчен мөмкин булырга тиеш, югары белем алу һәркемнең сәләтенә карап булырга тиеш.

2. Белем алу, кеше шәхесенең үсешенә, кеше хокукларына һәм төп ирекләргә хөрмәтне арттыруга юнәлдерелгән булырга тиеш. Белем алу расалар, дини оешмалар һәм халыклар арасында дуслыкка, килешүчәнлеккә, сабырлыкка булышырга, Берләшкән Милләтләр Оешмасына тынычлыкны саклауда ярдәм итәргә тиеш.

3. Ата-аналар үзләренең кечкенә балаларына белем алуның төрен сайлауда өстенлекле хокукка ия.

27 статья.

1. Һәр кеше җәмгыятьнең мәдәни тормышында иркле катнашырга, сынлы сәнгатьтән ләззәт алырга, фәннең үсешендә катнашырга, фән биргән байлыклардан файдаланырга хокуклы.

2. Һәр кеше, автор буларак, фәнни, әдәби, сынлы сәнгать өлкәсендәге хезмәте нәтиҗәләрен, үзенең әхлакый һәм матди ихтыяҗларын якларга хокуклы.

28 статья.

Һәр кеше бу Декларациядә язылган хокукларны һәм ирекләрне тулысынча тормышка ашыра торган халыкара һәм социаль тәртипкә хокуклы.

29 статья.

1. Һәр кеше җәмгыять алдында, үз шәхесе иркле һәм тулы үсешкә ирешкән җәмгыять алдында бурычлы.

2. Үзенең хокукларын һәм ирекләрен тормышка ашырган чакта, һәр кеше демократик җәмгыятьтәге гомуми мул тормыш, социаль тәртип, гадел әхлак таләпләрен канәгатьләндерә торган хокукларга һәм ирекләргә тулы хөрмәт тәэмин итә торган законлы чикләүләргә генә дучар ителергә мөмкин.

3. Бу хокукларны һәм ирекләрне тормышка ашыру Берләшкән Милләтләр Оешмасы максатларына һәм принципларына каршы килергә тиеш түгел.

30 статья.

Бу Декларациядәге бер нәрсә дә нинди дә булса дәүләткә, бер төркем шәхесләргә яисә аерым кешеләргә бу Декларациядә язылган хокукларны һәм ирекләрне юкка чыгарырга юл куела дип аңлатылырга тиеш түгел.